ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 30.09.2022 1283 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы белем бирү оешмаларында өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын карау һәм тәрбияләп тору өчен түләүдән азат итү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын карау һәм тәрбияләп тору өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән), гаиләләрдән алына торган түбәндәге түләүләрдән азат итәргә:

- Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында туклану, шулай ук балаларны карауны һәм тәрбияләп тору;
- Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында мәктәптә туклану.

2. Алабуга муниципаль районының белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

2.1. 1 пунктта күрсәтелгән ташламаларны белем бирү оешмасында тәрбияләнүченең ата-анасын (законлы вәкилен) өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакыруы турында хәрби комиссариат белешмәсе нигезендә бирергә;

2.2. өлешчә мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны кире кайтарган очракта, ташламаларны гамәлдән чыгаруны контрольдә тоту максатыннан, хәрби комиссариат белән хезмәттәшлекне тәэмин итәргә.

3. Алабуга муниципаль районының финанс-бюджет палатасында (Э.И. Садыйкова) Алабуга муниципаль районы белем бирү оешмаларында өлешчә

мобилизацияләү кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләреннән тәрбияләнүчеләрне тотуны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән гражданнарны өлешчә мобилизациялшү кысаларында хәрби хезмәт үткән вакытта барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA

Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович

Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Л.Ф. Нургаянов